## АВЫЛЫМ ТАВЫШЛАРЫ

*Луиза Батыр-Болгари көе*
*Наил Касыймов шигыре*

Шау-шулы шәһәргә бәйле
Булса да шул язмышым,
Һәр җөйме тыңларга сусап
Кайтам авылым тавышын.

*Кушымта:*
Җырлый чишмә, сайрый кошлар,
Җырлыйлар арышларым.
Һава сыман кирәк миңа
Авылым тавышлары.

Моңлы сандугач уята
Саф балачак хисләрен.
Яшьлек җырларын яңарта
Тальян моңы кичләрен.

*Кушымта.*

Туйлар уза, җырлап уза
Кыңгыраулы тавышы.
Авылымның моңнарыннан
Аермасын язмышым.

*Кушымта:*
Җырлый чишмә, сайрый кошлар,
Җырлыйлар арышларым.
Һава сыман кирәк миңа
Авылым тавышлары.